РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«8» декабря 2021 ел г. Альметьевск № 1764

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Балигъ булмаганның эмансипациясе (балигъ булмаганны тулысынча хокуктан файдалануга сәләтле дип игълан итү) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2019 елның 30 июлендәге 1361 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү сәбәпле, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Балигъ булмаганның эмансипациясе (балигъ булмаганны тулысынча хокуктан файдалануга сәләтле дип игълан итү) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2019 елның 30 июлендәге 1361 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

2 бүлекнең 2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.5. Хезмәт күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | Балигъ булмаган затның гаризасы (Регламентка 1 нче кушымта);<br>Балигъ булмаганнарның ата-аналарының яисә башка законлы вәкилләренең уртак гариза-ризалыгы (Регламентка 2 нче кушымта).<br>Мөрәҗәгать итүчеләрнең паспорты һәм аларның күчермәләре. | |

Зак. № 305-2000

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | Чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәве турында таныклык һәм аларның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе.<br>Балигъ булмаган баланың хезмәт эшчәнлеген раслый торган документлар (хезмәт шартнамәсенең (контрактның) яисә хезмәт кенәгәсенең күчермәләре, яисә кәгазьдә тиешенчә таныкланган хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр, яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә.<br>Гаризалар һәм документларның күчермәләре бер нөсхәдә (оригиналлар булганда) бирелә. | |

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ